КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 март г.Казань № 172

Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш), Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләү һәм килештерү тәртибе турында» 2008 елның 23 мартындагы 198 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләү һәм килештерү тәртибенең 23 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш), Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республи-

касы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021ел, 27 март, 172 нче
карары белән расланды

Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш), Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү
тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртиптә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш) (алга таба – схема проекты), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 12 статьясы белән билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан (алга таба – җирле үзидарә органнары) Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын (алга таба – схемага үзгәрешләр кертү проекты) килештерү регламенты билгеләнә.

1.2. Схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерүдә катнашучы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә федераль әһәмияттәге объектлар булдыру күздә тотыла торган, схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмәләрне килештерүгә һәм әзерләүгә вәкаләтле булган Татарстан Республикасы министрлыклары керә:

федераль транспорт (тимер юл, һава, эчке су), федераль әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;

федераль транспорт (газ, нефть һәм нефть продуктларын транспортлау өчен билгеләнгән торбаүткәргеч транспорт) өлкәсендә, энергетика өлкәсендә – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;

югары белем бирү өлкәсендә – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

сәламәтлек саклау өлкәсендә – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 10 статьясындагы 2 өлеше нигезендә башка өлкәләрдә – беркетелгән эшчәнлек өлкәсе нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары.

1.3. Схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерүдә катнашучы җирле үзидарә органнарына схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) нигезендә территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган яки урнаштырырга планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектлар территорияләрдәге әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый алган муниципаль районнар, шәһәр округлары, шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары керә.

1.4. Әлеге Тәртипне гамәлгә ашыру максатларында урнаштырырга планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектларның Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә йогынты ясау мөмкинлеге, Татарстан Республикасы территориясендә әлеге объектларның әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау мөмкинлеге өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә федераль әһәмияттәге объектларны урнаштыру планлаштырыла торган схема проектлары (схемага үзгәрешләр кертү проектлары) мәҗбүри килештерелергә тиеш. Башка мәсьәләләр, схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) әзерләүгә бәйле рәвештә, килештерелә алмый.

1.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнарының бәяләмәләре нигезендә территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасында схема проектыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы хәбәрнамәне алган көннән өч ай эчендә, ә схемага Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 26 статьясындагы 7 өлешендә каралган үзгәрешләр йә әлеге схема белән урнаштырылуы күздә тотылган федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өлешендә үзгәрешләр кертелгән очракларда (схемага үзгәрешләр кертү таләп ителмәгән очраклардан тыш) – территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасында схемага үзгәрешләр кертү проектыннан һәм аны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы хәбәрнамә кергән көннән бер ай эчендә мондый проектны килештерү яки килештермәү (мондый килештермәүне нигезләп) турындагы нигезләмәдән гыйбарәт бердәм документ формасында Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсен әзерләүне гамәлгә ашыра.

## II. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерү тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында схема проектыннан (схемага үзгәрешләр кертү проектыннан) һәм аны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә алган көннән ике эш көненнән дә соңга калмыйча, хәбәрнамәне Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә Татарстан Республикасының түбәндәге башкарма хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җибәрә:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына – транспорт комплексында дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм дәүләт идарәсен тормышка ашыру кысаларында килештерү өчен (Татарстан Республикасының юл-транспорт комплексы эшчәнлегенә йогынты ясау мөмкинлеге өлешендә);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына – ягулык-энергетика комплексы өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм дәүләт идарәсен тормышка ашыру кысаларында килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына – мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясенең бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләре кысаларында килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына – сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына – Татарстан Республикасы территориясендә урнаштырырга планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектларның әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау мөмкинлеге өлешендә килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына – урнаштырырга планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектларның Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә йогынты ясау мөмкинлеге өлешендә килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына – Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасына туры килү өлешендә килештерү өчен;

Татарстан Республикасының бүтән башкарма хакимият органнарына – беркетелгән эшчәнлек өлкәсе нигезендә килештерү өчен;

схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) нигезендә территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына – муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешенә урнаштырырга планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектларның йогынты ясау мөмкинлеге, муниципаль берәмлек территориясендә мондый объектларның әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау мөмкинлеге өлешендә килештерү өчен.

2.2. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасында схема проектыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы хәбәрнамәне алган көннән 30 көннән дә соңга калмыйча, ә схемага Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 26 статьясындагы 7 өлешендә каралган үзгәрешләр йә әлеге схема белән урнаштырылуы күздә тотылган федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өлешендә үзгәрешләр кертелгән очракларда (схемага үзгәрешләр кертү таләп ителмәгән очраклардан тыш) – территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасында схемага үзгәрешләр кертү проектыннан һәм аны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы хәбәрнамә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) белән килешү яки мондый проект белән килешмәү (мондый килешмәүне нигезләп) турындагы нигезләмәдән гыйбарәт схема проектына (схемага үзгәрешләр

кертү проектына) бәяләмәне Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрә.

2.3. Схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмәләр 2.2 пунктта күрсәтелгән срокта кермәгән очракта, схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) мондый органнар белән килештерелгән дип санала.

## III. Җирле үзидарә органнарының схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерү тәртибе

3.1. Муниципаль берәмлек башлыгы тиешле муниципаль берәмлек составына керә торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан схемасы проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерүне тәэмин итә.

3.2. Җирле үзидарә органнары территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасында схема проектыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы хәбәрнамәне алган көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, ә схемага Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 26 статьясындагы 7 өлешендә каралган үзгәрешләр йә әлеге схема белән урнаштырылуы күздә тотылган федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өлешендә үзгәрешләр кертелгән очракларда (схемага үзгәрешләр кертү таләп ителмәгән очраклардан тыш) – территориаль планлаштыруның мәгълүмати системасында схемага үзгәрешләр кертү проектыннан һәм аны нигезләү материалларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы хәбәрнамә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) белән килешү яки мондый проект белән килешмәү (мондый килешмәүне нигезләп) турындагы нигезләмәдән гыйбарәт схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмәне Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрә.

3.3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерү нәтиҗәләре әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.4. Схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) бәяләмәсенә муниципаль берәмлек башлыгы яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат тарафыннан имзалана.

2.3. Схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмәләр 3.2 пунктта күрсәтелгән срокта кермәгән очракта, схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) мондый органнар белән килештерелгән дип санала.

## IV. Схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсен әзерләү

4.1. Схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсе проектын әзерләүне Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) гамәлгә ашыра.

4.2. Әлеге Тәртипнең 2.2, 3.2 пунктларында күрсәтелгән сроклар тәмамлан-

ганнан соң, Министрлыкка җибәрелгән схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмәләр Министрлык тарафыннан схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсе проектын әзерләгәндә файдаланылырга тиеш түгел. Әлеге очракта схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) бәяләмә әзерләгән орган тарафыннан килештерелгән булып санала.

4.3. Схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерүдән баш тарту сәбәпләре турында мәгълүматы булмаган һәм (яки) схема проектын (схемага үзгәрешләр кертү проектын) килештерүдән баш тарту сәбәпләре буларак Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 12 статьясында билгеләнгән килештерү предметына туры килми торган дәлилләр булган схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмә Министрлык тарафыннан схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсе проектын әзерләгәндә файдаланылырга тиеш түгел. Әлеге очракта схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмә әзерләгән орган тарафыннан килештерелгән дип санала.

4.4. Әлеге Тәртипнең 2.2, 3.2 пунктларында билгеләнгән срок тәмамланганнан соң җиде эш көне эчендә Министрлыкка Татарстан Республикасының башкарма хакимият органыннан яки җирле үзидарә органыннан схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) белән килешмәү турындагы нигезләмәләрне үз эченә алган бәяләмә кергәндә, Министрлык схема проекты (схемага үзгәрешләр кертү проекты) буенча бердәм позиция эшләү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләре белән килештерү киңәшмәсен үткәрә.

4.5. Килештерү киңәшмәсендә кабул ителгән карар, килештерү киңәшмәсен үткәргән көннән ике эш көненнән дә соңга калмыйча, беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.6. Министрлык Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан кергән схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) бәяләмәләр яисә килештерү киңәшмәсендә кабул ителгән карар нигезендә әлеге Тәртипнең 2.2, 3.2, 4.4 пунктларында күрсәтелгән сроклар тәмамланганнан соң биш календарь көн эчендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсе проектын әзерләүне гамәлгә ашыра, аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

4.7. Схема проектына (схемага үзгәрешләр кертү проектына) Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсе Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 12 статьясында билгеләнгән һәм әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән вакыттан артып китмәгән срокларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә федераль әһәмияттәге объектлар төзү күздә тотыла торган, дәүләт сәясәтен эшләүне һәм норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органына җибәрелә.

Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш), Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

________________________________________
(адресат)

________________________________________________________________________________________,
(Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасын әзерләү гамәлгә ашырыла торган өлкә яки өлкәләр исеме)

өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын) карап,

__________________________________________________________________ дигән карар кылды.
(Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын килештерергә, баш тартуны нигезләп, килештерүдән баш тартырга)

(Татарстан Республикасының
________________________________
муниципаль берәмлеге исеме)

________________________
(подпись)

Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектыннан тыш), Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм территорияләрендә федераль әһәмияттәге объектлар урнаштыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

«Килештерелде»
Татарстан Республикасы
Премьер-министры

________________________

20___ ел, «___» __________

Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектына (Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына) Татарстан Республикасының җыелма бәяләмәсе

_______________________________________________________ бәяләмәләр нигезендә
(килештерүче органнарның һәм Татарстан Республикасы
җирле үзидарә органнарының нинди бәяләмәләре нигезендә)

___________________________________________________________________________
(Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләү,
Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын
әзерләү гамәлгә ашырыла торган өлкә яки өлкәләр исеме)

өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын (Россия Федерациясенең расланган территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын) карап,
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
_______________________________________________________ дигән карар кылды.
(Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасы проектын, Россия Федерациясенең расланган
территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын килештерергә, баш тартуны нигезләп,
килештерүдән баш тартырга)

_______________________________________